| Республика Татарстан<br>Глава Большенуркеевского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Зур Нөркәй<br>авыл җирлеге<br>башлыгы |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>2024 елның 11 ноябре | КАРАР<br>№ 2 |
|---|---|

Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Зур Нөркәй авылы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Карары:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 17.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй торак пункты с.Рәфыйков ур. 32 адресы буенча урнашкан Зур Нөркәй авыл мәдәният йорты бинасында 2025 елда Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау: «2025 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә ризамы, моннан тыш, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзалары, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1. Махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

2. Зур Нөркәй бистәсендә урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);

3. Зур Нөркәй бистәсендә җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча

хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында зиратлар территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу);
5. Зур Нуркәй авылында зиратларында агачларны кисү;
6. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Зур Нөркәй авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Сарман муниципаль районынын рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә.

4. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл жирлеге
Совет рәисе урынбасары Х.Ш.Шайхеразиев